
**Бергәләп өйрәник**



# Көз

**Әти-әниләр өчен методик ярдәмлек**

**(4-5 яшь)**

**Мәкальләр**

Көз бай булма, яз бай бул.
Көз кычкыра: «Уңдырам»,— дип, ә яз әйтә: «Тукта әле, мин нәрсә әйтермен»,— дип.
Көзге көн ул бала кебек: әле көлә, әле елый.
Күз өчен яз яхшы, авыз өчен көз яхшы.
Көзге көннән язгы төн яхшы.
Көзге юлга кием ал, язгы юлга азык ал.

***Шигырьләр***

Кырлар буш кала,
Яңгырлар ява.
Җирләр дымлана.
Бу кайчак була? (Көз.)

***

Сап-сары яфраклар
Җил искәч очалар.
Бөтерелә-бөтерелә
Җиргә үк төшәләр.

Көз килде. Үләннәр
Саргайды, шиңде.
Сап-сары яфраклар
Җиргә сибелде.

***

Бер кошка кызыгамын:
Тәпие кызыл аның.
Атлаган саен баш ия –
Гадәте кызык аның.
Гөлдер-гү, гөлдер-гү,
Бигрәк чибәр, кемдер бу?

**Хәрәкәтле уеннар**

***Курыкмыйм***

Балалар түгәрәк ясап басып торалар. Бер бала әбәкләүче итеп билгеләнә. Ул түгәрәк уртасына баса. Балалар, «курыкмыйм! Курыкмыйм!» дия-дия, бер урында ике аякта сикерәләр.Бу вакытта алар кулларын әле як-якка җәяләр, әле артларынаяшерәләр. Әбәкләүче, балалар кулларын як-якка җәйгәндә,аларны әбәкләп өлгерергә (кулы белән кагылырга) тырыша.Әбәкләнгән бала уеннан чыгарыла.

**Җырлы-биюле уен «Куш кулым».**

Урман буйларына менәм
Урман буе ямьлегә.
Бир кулыңны, мин дә бирәм,
Дус булырга мәңгегә.
Менә синңа уң кулым,
Менә синңа сул кулым.
Уң кулым да, сул кулым,
Менә синңа куш кулым.
Алма бакчасынакереп,
Алма ашыйсымкилә.
Син алмасы, мин чәчәге
Булып яшисем килә.